Япон кызы Накамура Мидзуки: «Минем йөрәгем – татар»

Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиадада ике Гран-при иясе ачыкланды. Бу исемгә Сабадан Ризәлә Йосыпова һәм Япониядән Накамура Мидзуки лаек дип табылды. Накамура татар сүзләрен беренче тапкыр әбисеннән ишеткән. «Татар теле – матур, мәдәниятле тел, аны бергәләп өйрәник, бөек телебезне саклыйк», – диде ул.

6 БИТ

Тукай да идеаль булмаган...

Казан федераль университетының Tataristica үзәге «XXI гасыр һәм Тукай» темасына дискуссия уздырды. Анда берничә мәсьәлә күтәрелеп, галимнәр арасында кызу бәхәсләр барды һәм төрле фикерләр яңгырады.

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 25.04.2017 | №44 (5806)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ТЫНЫЧЛЫК БУЛМАСА, ИЛ БЕРДӘМ БУЛА АЛМЫЙ

Казанда узган Татарстан халыкларының III съездында әлеге фикер еш кабатланды. Мең кеше катнашындагы зур чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Россия Президенты администрациясе җитәкчесе урынбасары Магомедсалам Магомедов, Россия халыклары ассамблеясы советы рәисе Светлана Смирнова, Россия Дәүләт Думасы рәисе урынбасары Владимир Васильев, Дагыстан башлыгы Рамазан Абдулатипов һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев билгеләп үткәнчә, әлеге форум республиканың иҗтимагый тормышында мөһим вакыйга булып тора.

– Халыклар съездын иң вәкиллекле форумдыр дип әйтергә була. Татарстанның этноконфессиональ өлкәдәге үсеш моделенә Россиядә дә, халыкара дәрәҗәдә дә ихтыяҗ зур булды. Аның күпмилләтле халкы республикабызның яңа тарихындагы хәлиткеч вакыйгаларны, замананың сынавын лаеклы уза. Чөнки без һәрвакыт төрле милләтләрне берләштерә торган рухи кыйммәтләргә йөз тоттык, милли үзенчәлекләр буенча бүлгәләүгә юл куймадык. Бүгенге съездның да шушы күркәм традициябезне ныгытуында шигем юк, – диде ул.

Магомедсалам Магомедов, үз чиратында, Россиядә яшәүче халыкларның үзара дус яшәве гасырлар буена килүен ассызыклап үтте. Ил җитәкчелеге дә моңа зур игътибар бирә дип, ул Россия Президенты Владимир Путинның сәлам хатын укыды. «Әлеге форум – Татарстан, гомумән Россия өчен мөһим вакыйга. Татарстан үзендә яшәүче халыкларның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклавы белән данлыклы. Ә иң мөһиме – ул кунакчыллыгы, халыклар арасында үзара аңлашу булуы, бер-берләренә ышаныч белдерүе белән аерылып тора. Республика һәр халыкның үзенчәлеген саклау мәсьәләләрен өстенлекле юнәлеш итеп куйган. Милли тел, мәктәп, мәдәният, мәгариф үзәкләренә ярдәм күрсәтү программалары алга таба да үстереләчәк», – диелгән иде Президент мөрәҗәгатендә.

Магомедсалам Магомедов сүзләренчә, Татарстан – социаль-икътисади потенциалы, инновацион технологияләр өлкәсендә лидер булуы белән генә түгел, милләтләр дуслыгы белән дә танылган төбәк.

→ Ахыры 4нче биттә.

Чиратта – сырхауханәләр

Беренчел медицина звеносын модернизацияләү программасы әзер

Кичә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2017-2018 елларга республикада беренчел медицина звеносын модернизацияләү һәм нығыту программасын хуплады. Әлеге проект нигезендә 197 медицина учреждениесен төзекләндерергә җыеналар. Бу максатларда 7,5 миллиард сум акча сарыф ителәчәк. Программа турында тулырак Татарстанның Министрлар кабинетында узган матбугат конференциясендә республиканың сәламәтлек саклау министры Адел Вафин сөйләде.

realnoevremya.ru

Эльвира МОЗАФФАР

Сырхауханәләр белән бәйле проблемалар – медицинаның иң авырткан урыныдыр, мөгаен. Табибка язылу проблемалары, биналарның иске булуы халыкта гел канәгатьсезлек уятты. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та бу хакта гел искәртә килде.

– Сырхауханәләр мәсьәләсенә җитди караш кирәк. Аеруча Казан, Чаллыдагы сырхауханәләр капиталь төзекләндерү таләп итә. Быел тагын бер кат анализ ясап, мөмкинлекләребезне чамалап, кайбер сырхауханәләрне, һичшиксез, капиталь ремонт программасына кертәчәкбез. Төрле медицина учреждениеләре бар: алга киткәннәре, эшчәнлеген камилләштерергә кирәк булганнары да. Халык бар җирдә бертөрле. Һәр кеше тиешле медицина ярдәме алырга тиеш, – дип белдергән иде Президент Сәламәтлек саклау министрлыгының коллегия утырышында.

Вәгъдәне озак көтәргә туры килмәде. Россия Президенты Владимир Путинның Федераль Җыелышына еллык юлламасында яңгыраган йөкләмәләрен үтәү максатыннан, Татарстан хөкүмәте беренчел медицина звеносын модернизацияләү һәм нығыту буенча программа әзерләде. Ул республика шәһәрләрендә, районнарында сырхауханә биналарына капиталь ремонт ясау һәм аларны заманча медицина җайланмалары белән тәэмин итүне күздә тота. Рөстәм Миңнеханов, бу зур һәм күләмле программаны гамәлгә ашыру республиканың барлык министрлыкларыннан һәм ведомстволарыннан, шулай ук муниципаль дәрәҗәдән дә тырышлык күрсәтүне таләп итә, дип белдергән.

Адел Вафин әйтүенчә, Татарстанда беренчел звено биналары соңгы тапкыр 2011-12 елларда төзекләндерелгән булган. Бүген 197 бина ремонт таләп итә. Аеруча Казан, Чаллыдагы сырхауханәләрнык искергән.

– Сәламәтлек саклау өлкәсендә беренчел звенода күп кенә эш башкарылды. Аеруча авыл җирлегендә модульле фельдшер-акушерлык пунктлары ачылды һәм төзекләндерелде. Беренчел звено эшчәнлегенә күп нәрсә бәйле. Республикада беренчел звенога караган 11690 табиб исәпләнә. Ашыгыч медицина ярдәме хезмәткәрләре күпме кешене миокард инфаркты, инсультлардан коткарып кала. Быел 75 бина яңартылачак дип ниятләнелә. Төзекләндерү вакытында медицина учреждениеләре тулысынча ябылмаячак, эшләвен дәвам итәчәк. Ремонт ясалырга тиешле 43 объектның проект-смета документлары май башында әзерләнеп бетәр дип көтелә, – дип таныштырды Адел Вафин.

Киләсе елга исә 122 объектка – күбесенчә хатын-кызлар консультацияләре, махсуслашкан сырхауханәләргә капиталь ремонт ясарга җыеналар.

Сырхауханәләрдә мохит тә үзгә булыр дип көтелә. Яңартылган медицина учреждениеләре республикада гамәлгә ашырыла башлаган «Дустанә сырхауханә – Татарстан стандарты» проекты нигезләнеп эшләячәк. Ягъни төп бурыч – халык өчен уңайлы шартлар булдыру. Монда пыяла тәрәзәле регистратура булмаячак дә юк, медицина персоналы һәр клиент белән янына басып сөйләшә. Табибның пациент белән аралашу вакыты да 15 минутка кадәр озайтылган. Авыру янына өйгә барырга туры килсә, моны махсус фельдшер төркеме башкара.

– Сырхауханәләрне модернизацияләү бер хәл. Иң мөһиме – кеше авырганда гына түгел, авыруын кисәтү өчен вакытында табибларга мөрәҗәгать итсен, – диде Адел Вафин.

Туристлык сезонына старт бирелә

Татарстанда туристлык сезоны 29 апрель көнне «Казан» гаилә үзәге янында «Чәчәк ат, Казан» дигән флешмоб белән ачылачак. Флешмоб нәтиҗәләре буенча видеоролик әзерләнеп, ул социаль челтәрләргә таратылачак. Флешмобта катнашучыларга күңел ачу үзәкләренә һәм музейларга билетлар уйнатылачак. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә спикерлар туристлык сезонында нинди яңа кызыклы чаралар оештырылачагын сөйләде.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Татарстанның Туризм комитеты рәисе Сергей Иванов сүзләренчә, май бәйрәмнәрендә туристлар тарафыннан сәфәр өчен сайланган Россия шәһәрләре арасында Казан – беренче өчлектә. Шәһәр кунакханәләрендә номерлар 70-80 процентка тулган. Былтыргыга караганда, туристларның саны быел 12-14 процентка күбрәк булыр дигән өмет бар.

– Бу сезонда вакыйга туризмына басым ясалачак. Урам фестивальләре, күргәзмәләр оештырыла. Июнь аеның төп вакыйгасы – ФИФАның Конфедерацияләр кубогы. Анда килгән кунаклар һәм казанлылар өчен махсус туристлык программалары һәм экскурсияләр каралган. Алар үз эченә Казанның истәлекле урыннарын гына түгел, Алабуга, Болгар, Зөя утрау-шәһәрчеген дә ала. Чаллыдагы «КамАЗ» заводы, Иннополис шәһәре белән дә таныша алачаклар. Экскурсияләргә билетларны Казанның туристлык-мәгълүмати үзәгендә, Казан үзәгендә урнаштырылачак чатырларда алырга була. Шунда ук республиканың төп туристлык үзәкләре схемасы картасын бушка алырга мөмкин булыр дип көтелә, – дип сөйләде ул журналистларга.

Казанның туризм үсешенә булышлык күрсәтү комитеты директоры Дарья Санникова сөйләвенчә, Казан «велотөн»ен уздыру быелгы планда да бар. Икенче тапкыр үткәрелә торган быелгы «Тәмле Казан» гастрономия фестивале исә татар аш-сулары остасы Юныс Әхмәтҗанов белән француз рестораторы һәм шеф-повары Поль Бокюзга багышлана. Фестиваль кунаклары анда француз һәм татар ризыкларын пешерергә өйрәнәчәк. Тагын бер яңалык – беренче тапкыр «Парижга тәрәзә» урам фестивале узачак. Әлеге фестивальдә мода күрсәтеләчәк, урам театрлары куелачак, фотосурәтләр күргәзмәсе оештырылачак. Июнь башында «Ретротрамвай» да сәяхәткә чыга, ул Елга портыннан Казан тимер юлына йөриячәк. 40 минутлык сәяхәт эченә Иске Татар бистәсе белән танышу да кергән. Май башында Кабан күлендә елга экскурсияләре ачыла. 30 апрельдән башлап һәр шимбә көнне «Туган авылым» комплексында «Казан» театральләштерелгән фольклор шоу күрсәтеләчәк. Үткән елны анда 5,5 мең кеше булган.

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы да берсеннән-берсе кызыклы чаралар әзерләгән. 9 майда аның территориясендә «Җиңү флэшмобы» үтәр дип көтелә. 20 майда «Казан Кремлендә көн һәм төн» акциясе кысаларында концерт, интерактив экскурсияләр, мастер-класслар оештырыла.

Татарстанның туристлар яратып өлгергән Чистай, Болгар, Зөя, Алабуга шәһәрләре дә туристларны кабул итәргә әзер.

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы директоры урынбасары Лилия Сафина да журналистларга кызыклы программалар әзерләнүен сөйләде. 1 майда урта гасыр һөнәрчелек үрнәкләре белән таныштыручы «Болгар бистәсе» мәйданчыгы эшләячәк. «Болгар мәйданы» мәйданчыгында баһадирлар эстафетасы була. Болгар быел круиз теплоходларын да кабул итәчәк. Быелгы сезонда «Музей урамы» төбәкне өйрәнү комплексы да үз ишекләрен ача.

«Зөя утрау-шәһәрлеге» музее директоры Артем Силкин сүзләренчә, 29-31 майда – «Безнең әйләнә-тирәдәге музыка» бөтенроссия классик музыка фестивале, 12 июньдә хор музыкасы фестивале үз тыңлаучыларын кабул итәчәк. Июль һәм август Зөядә Театр сезоны эгидасы астында үтәчәк. Сентябрьдә «Зөя ухасы» пешереләчәк.

Алабуга музеенда быел «Ират эше» һәм «КПССка дан!» кебек яңа интерактив мәйданчыклар эшләячәк. 4-6 августта традициягә кергән «Спас ярминкәсе» була.

Чистай да кунаклар көтә. 18-20 августта анда «Әдәби Чистай» авторлар җыры фестивале үтәчәк.

- Узган елны май бәйрәмнәрендә Казан Кремле музей-тыюлыгында 192 101 турист булган (2015 елда – 58 458).
- Болгарда 16 254 кеше булып киткән (2015 елда – 9 584).
- Бәйрәм көннәрендә Зөя утрау-шәһәрчегендә 17 059 кунак булган (2015тә – 11 957).
- Алабуга үзендә 14 263 туристны кабул иткән.

«Безнең монда тамак тук»

Автор фотосы

АРМИЯ

Россия Кораллы көчләренә чакырылыштагы хәрби хезмәткә алынган ир-егетләрнең «Патриот» республика җыелу пунктында үткәргән бер-ике атна вакытлары хәрби хезмәт срогына керми. Чакырылыштагы бер елны хәрби частьларга кузгалган көннән, хәтта ки сәгатьтән башлап санарга кирәк.

Дамир БӘДРИЕВ

Татарстаннан 15 июльгә кадәр дәвам итәчәк чакырылышта 4 меңгә якын ир-егет армиягә алыначак. Төрле хәрби частьларга 21 апрельдә кузгалган якташларыбызга Татарстан Республикасы хәрби комиссары Сергей Погодин, Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская, протоиерей Виталий Тимофеев һәм Тимергали хәзрәт Юлдашев намуслы хезмәт итеп, исән-сау әйләнеп кайтырга дигән теләкләрен җиткерделәр.

Генерал-майор Сергей Погодин таныштырганча, Казандагы «Патриот» үзәге – Россиядә иң яхшы пунктларның берсе.

– Биредә кагыйдәләр хәрби частьтагы кебек. 30 офицер тәүлек дәвамында тәртип сагында тора, бина тыштан һәм эчтән видеокүзәтүдә. Кемнең дә булса әйберен урлау, юашракларны кыерсыту дигән нәрсә юк, – дип катгый төстә җавап кайтарды республика хәрби комиссары Сергей Погодин, кызыксынып биргән соравыма.

Сәрия Сабурская да: «Чакырылыштагы ир-егетләрнең хокукларын яклыйбыз һәм саклыйбыз», – дип ышандырды. Ул якташларыбызны, әгәр хәрби частьларда Уставтан тыш гамәлләргә, ягъни кыерсытуларга дучар булсалар, һич шикләнмичә хәбәр салырга чакырды. Армиягә алынган һәр ир-егеткә хокукый белешмә һәм кирәкле телефоннар китапчыгы биреп җибәрелә.

«Патриот» җыелу үзәгендә булачак солдатларга банк картасы бирелә. Ай саен әлеге картага – 2 мең сум, ә ятимнәргә 3 мең сум акча күчереп барыла. Ятимнәргә кәрәзле телефон бүләк ителә. Тулы гаиләдәгеләргә: ата-анага һәм чакырылыштагы хәрби хезмәткә алынучыга сим-карта тапшырыла. Элемтә операторларыннан ташламалар каралган.

Берничә сәгатьтән хәрби частьларга кузгалачак егетләрнең уй-фикерләрен сораштым.

Илнур ГАЙНЕТДИНОВ,
Әлмәт шәһәре:

– «Патриот» үзәгендә тәртип бик көчле. Безнең монда тамакларыбыз тук булды. Кытай чигендәге Нахабино шәһәрчегенә билгеләделәр. «Чик күренеп тора», – диделәр.

Фирзәр ХӘМИДУЛЛИН,
Балык Бистәсе районы:

– Яңа Арыш авылыннан мин. Әти хәрби хезмәттә булган, егет кешегә армиягә барып кайту кирәк. Дулкынлану бар инде күңелдә.

Дамир АЛИМОВ,
Биектау:

– Армиягә баруны кирәк саныйм, бер ел күп вакыт түгел. Нахабино шәһәрчегенә билгеләделәр. Исән-сау әйләнеп кайтырга язсын инде.

Генерал-майор Сергей Погодинның да теләге шул: «Илебез күгe коешлы булсын! Матур хезмәт итеп, ныгып кайтыгыз!»

Мин татарча сөйләшәм: ачык, текә, яшьләрчә

26 апрель – Габдулла Тукай туган көнендә Казан шәһәре, аеруча Бауман урамы бары татар телендә сөйләшәчәк. 12 ел рәттән узучы «Мин татарча сөйләшәм» акциясен Бөтендөнья татар яшьләре форумы активистлары гына түгел, үз теленә тугры барлык яшьләр дә зарыгып көтеп ала.

– «Мин татарча сөйләшәм» акциясе – алдынгы, кызыклы, ачык, бәйрәм рухында барган гражданлык позициябезне билгеләү чарасы. Ун ел дәверендә нинди генә яңа форматлар уйлап тапмадык: вело-автохәрәкәт, фотомарафон оештырдык, урамга чыгып, сәүдә үзәкләрен татарча сөйләштердек. Үзебез ниндидер архитектур формалар ясарга тырыштык. Быел да акция кысаларында унга якын чара оештырылды. Татар теле дәресләкләрдә генә калмасын өчен, замана белән бергә атларга, кәттә булырга тырышабыз, – диде Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе Тәбрис Яруллин.

Быел да «Мин татарча сөйләшәм» активистлары өч төрле бәйге оештырган. Беренчесендә республиканың 150гә якын мәктәбе катнашкан. Биредә укучылар төрле оешмаларда, дәүләт хезмәтләрендә икетеллелек законын куллану очракларын тикшергән. Икенче бәйге яшь архитекторлар арасында уздырылган. Анда Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының 30га якын студенты катнашкан. Алар «Ә» хәрефе белән бәйле кече архитектур объект ясарга тиеш булган.

– Эскизлары буенча беренче урын алган эшне «Куллар» дигән дизайн студиясе тормышка ашырырга ярдәм итте. Шулай итеп, бәйрәм көнне шәһәр үзәгендә 400 килограммлы, 3 метр биеклектә «Ә» хәрефе калкып чыгачак. Акция тәмамлангач, бу хәреф төзелеш университеты ишегалдында торачак, – диде Тәбрис Яруллин.

Акция кысаларында узачак өченче бәйге – музыкаль юнәлештә. Бәйрәм көнне Бауман урамында җиңү яулаган үзенчәлекле, бәйсез, татарча иҗат итүче музыкаль төркемнәрне ишетеп булачак.

«Мин татарча сөйләшәм» акциясенең иң кызыклы юнәлешләренең берсе – «Татар дозор». Гадәттәгечә, ул төп чарадан берничә көн алданрак оештырыла. Быел 400гә якын «татар дозор»ы урамга 22 апрель көнне чыкты. «Dərdemənd» дип аталган квест уен бөтенләй яңа форматта оештырылды. 50 команда Закир Рәмиевнең Иске Татар бистәсе, Бауман урамы, Ирек мәйданы, Казан Кирмәне буенча таралган алтын таңкаләрен җыеп йөрде.

«Мин татарча сөйләшәм» күңел ачу чарасы гына түгел. Беренче чиратта ул – икетеллелекнең кулланылышына мониторинг ясау, законнар үтәлешен тикшерү. Шуңа да киләсе елдан аның кысаларында оештырылачак «Татар дозор» ел дәвамында эшли торган, инде үз тормышы белән яшәүче аерым бер проект булачак.

– Узган ел без икетеллелек законнарын саклаучы оешмаларның рейтингын төзү өчен махсус сайт булдырдык. Узган елларда министрлыкларны тикшергән идек, быел исә Казан шәһәре районнарына кагылган барлык идарәләрнең элмә такталарын, сайтларын тикшердек. Татарча иң начар сөйләшүче район булып Совет районы танылды. Татар телендә мөрәҗәгать иткәч, алар безгә бик дорфа җавап бирде. Башка районнар исә татарча хезмәт күрсәтүче кешеләрне табарга тырышты. Мин аерып Иске шәһәр префектурасы белән Туристлык комитетын әйтер идем. Алар, нинди генә сорау булмасын, мәгълүматны саф татар телендә җиткерә. «Антипремия»без оешмаларга уңай тәэсир итә, ләкин сәхнәгә чыгып «антипремия» алырга әле бер оешманың да батырлыгы җитмәде, – диде «Мин татарча сөйләшәм» хәрәкәте активисты журналист Римма Бикмөхәммәтова.

Акция 16.00 сәгатьтә Бауман урамындагы сәгать каршында узачак.

Алисә САБИРОВА.

ФОРУМ

Җәмәгать оешмалары – кодрәтле көч

Кичә Казанда Идел буе федераль округы буенча актив гражданнарның һәм коммерциячел булмаган оешмаларның «Содружество» форумы ачылды.

Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиев форумда катнашучыларга Президент Рөстәм Миңнехановның котлау сүзен җиткерде. «Татарстанда 5,5 мең җәмәгать оешмасы юридик зат буларак теркәлеп, эшчәнлек алып бара. Республикада гражданлык институтларын үстерүгә әһәмият бирелә. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының гражданлык институтларын үстерүгә ярдәме зур. Республикада коммерциячел булмаган оешмаларга теләктәшлек максатларында, 1 миллиард сум акча күчерелде. Дәүләт белән җәмәгать оешмаларының үзара хезмәттәшлеге зарур», – диелгән әлеге котлауда.

– Татарстанда 173 милләт һәм халык вәкилләре яши. Милләтара дуслык һәм татулык хөкем сөрә, – дип, үз фикерләрен җәвап итте Васыйл Шәйхразиев. – Президент Рөстәм Миңнеханов кеше капиталының мөһимлеген гел искәртеп тора. Халыкка уңайлы тормыш-көнкүреш шартлары тудырырга омтылабыз. Уңышлар җитәрлек, ләкин чишелеш көткән мәсьәләләр дә бар. Даими өйрәнәбез, Россия һәм дөнья тәҗрибәсен кулланабыз. Хакимиятнең, җәмәгать оешмаларының һәм эшкуарлыкның үзара хезмәттәшлеге бик мөһим.

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Анатолий Фомин республикада гражданлык институтларының, ягъни җәмәгать оешмаларының, ресурс үзәкләренең актив эшчәнлек алып барулары турында сөйләде.

– Балаларны ватанпәрвәрләр итеп тәрбияләп үстерү аеруча әһәмиятле, – дип басым ясады Анатолий Фомин.

Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы Елена Тополева-Солдунова: «Казанда еш булам, Казанны яратам! – дип башлады үзенең чыгышын. – Форум илебезнең 20 төбәгендә үткәрелде инде. Үзара тәҗрибә уртаклашабыз, бер-беребездән өйрәнәбез».

Казандагы форумда коммерциячел булмаган оешмаларга хакимият органнары һәм бизнес вәкилләре белән ничек эш алып бару кирәклеге аңлатылды. Россия Федерациясе Президенты грантларына конкурска үз эшчәнлегеңне дөрес итеп күрсәтә белү дә кирәк. Быел грантлар 7 миллиард сумга кадәр тәшкил итәргә дә мөмкин.

– Медицина һәм мәгариф өлкәләрендә социаль проектлар гамәлгә ашырыла. Социаль проектлар алар акчалы өлкә түгел. Коммерциячел булмаган оешмалар әлегә бу юнәлештә киң эшчәнлек алып бармады. Хәзер аларны да җәлеп итү күздә тотыла. Теләктәшлек йөзендә, коммерциячел булмаган оешмаларга 2017-2020 елларда тагын 1 миллиард сум акча бүлеп бирү каралган, – дип өметләндереп җибәрде Васыйл Шәйхразиев.

Рәдиф КАРАГАЙ.

Тынычлык булмаса, ил бердәм була алмый

→ Ахыры.
Башы 1нче биттә.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

– Татарстан – милли сәясәтне алып бару буенча Россия субъектлары арасында күренекле лидер. Биредә яшәүче һәр халыкның телен, мәдәниятен үстерү буенча зур эшләр алып барыла, – диде ул.

Әмма шул ук вакытта ул уяулыкны да югалтырга ярамый, илдә радикализм, террорчылык, экстремизм кебек куркыныч күренешләр бар, дип белдерде.

Россия Дәүләт Думасы рәисе урынбасары Владимир Васильев Дәүләт Думасы рәисе Вячеслав Володинның сәламләү сүзләрен җиткерде. «Татарстанда милләтара һәм конфессияара тынычлыкның уникаль тәҗрибәсе тупланды. Татарстан халыклары съезды әлеге күпьеллык тәҗрибәне тагын да ныгыта» диелә аның мөрәҗәгатендә.

Дагыстан башлыгы Рамазан Абдулатипов съездга буш кул белән килмәгән. Ул Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә «Дагыстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды. Аның үзеннән соң булдыклы команда калдыруын билгеләп үтте.

– Әлеге көчле команда иң болгавыр елларда да республика халкының, бөтен Россиянең мәнфәгатьләрен яклый алды. Татарстан халыклары ассамблеясы да уңышлы эшләп килә. Сез үзегезгә булган бөтен ышанычны аклый алдыгыз, сүз кешеләре булуыгызны исбатладыгыз. Шуның белән республикагызны да үстерәсез. Әлеге эшне Минтимер Шәймиев башлады, аны Рөстәм Миңнеханов дәвам итә. Ассамблея җитәкчесе булып нәкъ менә Фәрит Мөхәммәтшинның торуы да мөһим. Татарлар Россияне бизи. Алар Россиянең җитештерү буенча алдынгы төбәге, мәдәни, спорт элитасы булып тора. Без һәм татарлар арасында охшашлыклар да бар. Дошман теләсәгез, иң яхшы дошман – дагыстанлы, ул сине йөз ел эзәрлекләячәк, дус кирәк булса, иң яхшы дус – дагыстанлы, ул синең өчен гомерен дә бирергә әзер. Татарлар да шундый ук, тау кешеләренә генә хас ул. Дагыстан халкы татарларны ярата. Татарлар – Кытай чикләреннән Европага кадәр яшәгән бөек халык, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында, Россия Президенты Владимир Путинның съездда катнашучыларга сәламләү сүзе җибәрүе аның милли сәясәт мәсьәләләренә зур игътибар бирүен күрсәтә, дип билгеләп үтте.

– Россия дәүләтенең милли сәясәт стратегиясе кабул ителде, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык оешты, дәүләт программалары эшләп килә. Татарстанда да милли сәясәт программалары уңышлы эшли. Дини оешмалар да активлык күрсәтә. Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе зур эшчәнлек алып бара. Халыклар ассамблеясы, иҗтимагый оешмалар, дин оешмалары, республиканың абруйлы кешеләре – барысы бергә эшләп, шундый тотрыклылыкка ирешә алдык. Татарстанның көче һәм уникальлеге – халыклар дуслыгында. Безгә чит төбәкләр, чит илләрдән дә укырга, эшләргә, кайберләре яшәргә дә киләләр. Тынычлык булмаса, ил, республика бердәм була алмый, – диде ул.

Гали Хәсәнов, башкорт милли-мәдәни оешмасы җитәкчесе (Түбән Кама):

– Татарстанда яшәүче халыклар бер-берләренә хөрмәт белән карый. Халыклар ассамблеясында 36 милли-мәдәни автономия эшли. Нинди генә бәйрәм булмасын, без автономия җитәкчеләре бер-беребезне котлыйбыз, бәйрәмнәрне калдырмаска тырышабыз. Очрашканда, кул биреп кенә түгел, кочаклашып күрешәбез. Съезд кебек зур чаралар безне тагын да берләштерә.

Геннадий Макаров, музыка белгече, фольклорчы галим (Казан):

– Милләт эчендә төрле этник төркемнәр яши. Аларның һәрберсенең үз үзенчәлеге, үз культурасы, йолалары бар. Минә шуларны саклап, санлап, югалтмыйча үстерәсе иде. Ә моның өчен этнобелгечләр кирәк. Һәр милләт, шулай ук дәүләт кайгыртырга тиеш моны.

Нусрат Муфталиев, рутуль милләте вәкиле (Югары Ослан):

– Без – аз санлы халык. Бөтен дөнья буенча 25 мең кеше исәпләнәбез. 100гә якын рутуль Татарстанда яши. Без бирегә үзебезне чит халык итеп сизмибез, районда яшәүче 20ләп милләт вәкиле белән дуслара мөнәсәбәттә торабыз. Татарстан Россия төбәкләре арасында шуның белән аерылып тора да инде.

Абдуманоб Абдусаттаров, үзбәк милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе:

– Татарстанда милләттәшләребез күп яши. Республикага эшкә килүчеләрнең саны артып тора. Милли-мәдәни автономиябез дә актив эш алып бара. Ел дәвамында 20ләп чара уздырабыз, аеруча Нәүрүз бәйрәме зур масштабта уза. Эшкә килгән ватандашларыбызга яңа җирлеккә җайлашырга булышабыз, проблемаларын хәл итәбез. Яшьләр белән дә тыгыз элемтәдә торабыз, Үзбәкстаннан килгән 2 меңнән артык студент бирерә укый. Яшьләр арасында «Үзбәкстан чибәре» дигән конкурс оештырыла, бию ансамбльләре эшли. Телебезне, мәдәниятебезне саклап калырга мөмкинлекләр тудырганы өчен, республика җитәкчелегенә рәхмәтебезне җиткерәм.

Тукай да идеаль булмаган...

Узган атнада Казан федераль университетының Tataristica үзәге «XXI гасыр һәм Тукай» темасына дискуссия уздырды. Анда бернича мәсьәлә күтәрелеп, галимнәр арасында кызу бәхәсләр барды һәм төрле фикерләр яңгырады.

ШАГЫЙРЬНЕҢ БӨЕКЛЕГЕ НИДӘ?

Күтәрелгән сорауларның беренчесе Тукайның бөеклеге турында иде. Татар яшьләре активисты Рәдиф Кашапов «Тукайны идеаллаштыру, символ дәрәҗәсенә күтәрү аны халыктан ерагайта» дигән фикерен белдерде.

– Минем өчен Тукай, беренчедән, сәламәтлеген бик иртә туздырган кеше, икенчедән, коллега – иҗат кешесе, өченчедән, халык символы. Ә игл булгач, ул халыктан ерагая. Урамга чыгып сорап карагыз, күпләр Тукайның ике-өч шигырен генә әйтә ала, – диде.

Аңа җавап итеп Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев Тукайның халыктан ерагаюы турындагы фикер белән килешмәвен әйтте.

– Аның туууына 130 еллыгына багышлап 13 басма чыкты. Шул китапларны кибетләрдән сорап карагыз әле, таба алырсызмы? «Тукай турында ядькарләр»нең ике томлыгын чыгардык. Эзләп карагыз, таба алырсызмы? Аларны халык шунда ук алып бетерде. Чит илләрдә дә аны яхшы беләләр. Тукай әле ул шагыйрь генә түгел, безнең милләтне үз тирәсенә җыючы кеше дә. Бөек шагыйребез булмаса, безнең милләт тагын да таркаурак булыр иде, – диде.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев фикеренчә, олы шагыйрьләрне һәр чор, һәр буын үзенчә кабул итә. Тукайны замандашлары бер төрле – бөек итеп кабул иткәннәр, 20нче елларда башка төрлерәк булган. Анда вак буржуаз дип әйтүләр бар. 50нче елларда Тукай – халык шагыйре, совет режимы вакытында аны шул вакыттагы идеологиягә туры китереп кабул итәргә тырышу булган. Зөфәр Рәмиев әйтүенчә, бүген андый басым юк, хәзер инде ничек бар, шулай кабул итәргә тиешбез.

Татар язучысы Рабит Батулла исә шагыйрьнең бөеклеген үзенчә дәлилләде. Аның фикеренчә, Габдулла Тукай белән Александр Пушкинны, Гаяз Исхакый белән Лев Толстойны чагыштыру дөрес түгел.

– Бу ике якны да кимсетә, чөнки Тукай белән Пушкин – икесе ике бөеклектә, аларны чагыштырырга ярамый. Пушкин ул – аристократ, хәерче түгел. Ә Тукай бит башка. Толстой белән Пушкин: «Теләңне бетерәләр. Динеңне сыталар. Милләтебез бетә», – дип борчылмаган. Алар үз илләрендә рәхәтләнеп яшәгән. Тукай белән Исхакый телне, динне саклап калыр өчен берсе чирләшкәгә әйләнгән, икенчесе төрмәдән төрмәгә йөргән. Аларның бөеклеге шунда. Хәтта мин әйтер идем, Тукай Пушкинга караганда да бөегрәк түгел микән әле? Тукай – асфальтны бәреп чыккан үлән кебек. Сәнгатьнең бөтен күзәнәге – Тукайда. Моны бөек дими, ни дисең? Ул упкынга бара торган халыкны, үзенең чәрдәкләнүен белә торып, күкрәге белән каплаган, упкынга төшеп барган халыкны саклап, үзе сытылган кеше. Тукай ул – шәм, шәмнең яктылыгы еракка киткәч кенә төшә, Тукай бездән ерагайган саен, күбрәк яктыртачак. Аны ничек бөек димисең?! – дип белдерде.

ТУКАЙНЫҢ КАЙСЫ КҮЗЕНӘ АК ТӨШКӘН?

Дискуссия барышында галимнәр, белгечләр Тукайның барлык кимчелекләрен, җитешсез якларын күрсәтергә кирәкме-юкмы дигән сорауга да җавап эзләде.

– Тукайның уңмы, сулмы күзенә ак төшкән. Моны бүгенгә кадәр ачыкламаганбыз әле. Фән бар икән, без үзебезнең даһиебызның кайсы күзенә ак төшкәнлеген дә белергә тиеш, – диде Рабит Батулла.

Язучы фикеренчә, Тукайны изге итеп кенә күрсәтү дөрес түгел.

– Тукайны без идеал итеп күрсәтергә тырышабыз, аның кечкенә генә кимчелекләрен дә матбугатка чыгарырга риза түгелбез. Ләкин гайбәтләр дә, дөресе дә бар бит. Башка даһилар турында бөтен ярамаган якларын да ачалар, безнең менталитет шундыймы ул, гел изге итеп күрсәтәбез. Вафа Бәхтияров истәлекләрендә Тукайның кызык якларын да яза. Фән булгач, бөтен ягын да тикшерергә кирәктер дип уйлыйм мин, – ди язучы.

Татар энциклопедиясе һәм тәбәкне өйрәну институты директоры, Татарстан фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев тә бу мәсьәләгә карата үз фикерен җиткерде.

– Мин, тарихчы буларак, кайбер тарихчыларның хаталарын күрәм: без кайвакыт тарихта бары тик теләгәнне генә күрәбез. Галим Михайлов үз хезмәтендә, Тукайның үлеменнән соң 100 еллыгына кадәр булган күпчелек язмаларны барлап чыккан һәм кызыклы нәтиҗәгә килгән: күп очракта Тукайны бары тик инструмент итеп файдаланганнар. Аннан интернационалист та, патриот та, милләтче дә, атеист та ясаганнар. һәм Тукайның иҗаты – икенче планга, шәхесе өченче планга калган. Тарихта бөтен якларны бергә аңларга, бөтен нечкәлекләрне аек акыл белән күрсәтергә кирәк. Кызганычка, күп вакыт без Тукай – бөек, чөнки ул бөек дип кенә бәялибез. Тукай да кимчелексез кеше түгел. Тукайның бөтен мохитен аңларга тиешбез. Аның яшәгән шартларын, чордашларын да белергә кирәк. Шул вакытта гына чын Тукайны күрә алабыз дип уйлыйм. Аның бөтен ягын да күрсәтергә кирәк, тик кемгә һәм ничек иконен уйлау зарур, күпертергә, сенсация артыннан куарга ярамый, – дип әйтте Искәндәр Гыйләҗев.

Язучы Илфак Ибраһимов аның белән килешеп, ниндидер кимчелекләрне язганда, акыл белән килергә, фактларга таянырга кирәклеген әйтте. Разил Вәлиев тә, Тукайның кимчелеген күрсәтмәү аны тулыканлы шәхес итми, дигән фикердә. Әмма мәктәп укучыларына аларны күрсәтергә кирәкми, дип саный.

Казанның 20нче гимназиясендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлшат Фәхретдинова да шушы ук фикердә тора.

tatar-inform.ru

– Автобиографик повестен сөйләгәндә дә, бала аны йөрәгә аша үткәрә, сөйләгәндә күзләренә яшь тула. Тукай әсәрләренә нигезләнеп эшләнгән мультфильмны рус балалары дә йотлыгып карый, – диде.

Бу мәсьәләгә карата Рузәл Мөхәммәтшин да үз фикерен җиткерде.

– Аның әсәрләре, иҗаты бар, нинди генә мәгълүматлар булса да, шәхсән минем өчен Тукайның дәрәҗәсе төшмәячәк. Без капчыкта ятмый, кимчелекләрен дә күрсәтергә кирәк. Есенинны бит бөтен барлыгы белән сериалларда да күрсәтәләр. Аңа карап, «Ак каен» шигырен укудан туктамыйлар, – диде.

ЯҢА ФАКТЛАР

Быел татар җәмәгатьчелеге Тукай көннәрен зур канәгатьлек хисләре белән каршы ала. Чөнки, ниһаять, күптән көтелгән «Тукай энциклопедиясе» дөнья күрде. Зөфәр Рәмиев «Тукай энциклопедиясе»нең Тукайны өйрәну фәненең дәрәҗәсен шактый тулы чагылдырыун билгеләп узды.

– Бу эш 20 еллап алып барылды. Былтыр Тукайның 130 еллыгына эшләнеп бетте һәм хәзерге вакытта басылып чыкты. Энциклопедиягә шагыйрьнең 780ләп әсәре кертелде, аларга анализ биреледе. Аларны галимнәр фәннең үсеш дәрәҗәсеннән, бүгенге карашлардан чыгып характерлады, – диде ул.

Зөфәр Рәмиев энциклопедиягә 2360 мәкалә кертелгәнен хәбәр итте.

– Һәр мәкаләне язар алдыннан, авторлар Тукайның иҗатын, истәлекләрен өйрәнделәр, архивларда булдылар, яңа фактлар да ачыкланды. Мәсәлән, Шәрифә карчыкны Тукай үзенчә сурәтли. Архивта тикшерү нәтиҗәсендә, Шәрифә карчыкның исеме Мөхәммәди кызы Шәрифәҗамал булуы, аның 1895 елда үлүе кебек фактлар ачыкланды. Аннары гомер буе «Исемдә калганнар»да Зиннәтуллага ияреп килгән алты балалы тол хатын дип яздылар. Тикшерү нәтиҗәсендә бу Зиннәтулланың үз балалары булуы ачылды. «Алты бала күгәрчен» дип Тукайның чит күрүе дөрес түгел. Менә шундыйрак яңалыклар күп булды. Әсәрләрнең кайда, кайчан язылуы турында да яңа нечкәлекләр очрады. Тукайны музыкада, рәсем сәнгатендә, театрда чагылдыруда да бик күп яңалыклар булды, – дип сөйләде Зөфәр Рәмиев.

Тукайның иҗатына, тормышына кагылышлы яңа ачылган фактлар турында «Тукай – ядкярләрдә» фәнни басмасы авторларының берсе Рәмил Исламов та сөйләп китте.

– Тукай Троицкига кымыз белән дәваланырга барганда, аны Уфадан Габделбарый Баттал озата, ул Чиләбедәге бер байга каршы алырга дип телеграмма суга. Без ул Заһир Галиевнең бүгенгә Биектау районы Наласа авылыннан чыкканын, туган-үлгән елларын ачыкладык, – диде.

Рәмил Исламов әйтүенчә, фактлар каршылыгы да бар.

– Истәлекләрне өч төргә бүлергә мөмкин. 1917 елга кадәргеләрендә объективлык ярылып ята, 60нчы елларда бераз төреп бирүләр башлана, аннан соңгы дәвер дә бар. Әлбәттә, без аларның берсен дә иләк аша үткәреп, төшереп калдырмадык. Укучы үзе күрсен, карасын һәм фикерен белдерә алсын, дидек. Истәлекләрне язып алганда, һәркайсы Тукайны яхшырак белүен күрсәтергә тырышкан. Елларны бутаган очраклар да бар. Андый чакларда астөшермәләр ясап, башка чыганакларны да күрсәтеп бардык, – диде.

Әмма «Тукай энциклопедиясе»нең ни сәбәпле укучы кулына килеп ирешмәве генә аңлашылмый. Казан федераль университеты доценты Миләүшә Хәбетдинова әйтүенчә, әлеге хезмәт дәүләт программасы акчасына чыгарылганлыгын, шуңа күрә ул Татарстанның Мәгарифне үстерү институтында саклангалыгын җиткерде.

– Без укытучылар булсак та, энциклопедиянең бер генә томын да күрмәдек әле. Бу бик зур мәсьәлә, – диде.

Филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры Хатыйп Миңнегулов та, Тукай энциклопедиясе һәр мәктәптә, китапханәдә булырга тиеш, дип саный. Әлеге мәсьәләдән кала, зыялылар моңа кадәр заман таләпләренә туры килми дип гаепләгән Тукай сайтының бер ел дәвамында яңартылмавына да борчу белдерде.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

«Минем йөрәгем – татар»

Апрель – туган тел, Тукай ае. Телне саклау, үстерүгә юнәлтелгән чаралар бу араларда аеруча еш уза. Шуларның берсе – Бөтенроссия туган тел форумы – меңләгән укучыукытучыны «Баскет-холл» спорт сараена җыйды. Форум кысаларында «Ана теле» онлайн мәктәбеннән актив файдаланучы, иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы, иң милли мәктәпләрне, «Илһам» яшь язучылар бәйгесендә, Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиадада җиңүчеләрне – барлыгы 200ләп кешене бүләкләделәр.

Эльвира МОЗАФФАР

ТЕЛ БУЛМАСА, МИЛЛӘТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ ЮК

Олимпиадага аерым тукталыйк. Бу чара быел үзенә күрә юбилеен уздыра. Олимпиада үткәрелә башлаганга биш ел булган. Беренче елларда анда бары меңнән артык кеше генә катнашса, быел 15 меңләп укучы көчен сынаган. Катнашучылар арасында Россиянең 25 субъектыннан, Австралия, Төркия, Казахстан, Япония, Үзбәкстан, Бельгия, Франция, Канада кебек барлыгы 13 чит илдән дә вәкилләр бар. Чит илдә татар телен өйрәнүчеләр өчен биремнәр катлаулылык дәрәҗәсе буенча аерылып торган. Чараның төп максаты – катнашучыларның ничә балл җыюын ачыклау түгел, татар теленә дөнья күләмендә кызыксыну уяту. Елдагыча, татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиадада ике Гран-при иясен билгеләделәр. Бу исемгә Сабадан Ризәлә Йосыпова һәм Япониядән Накамура Мидзуки лаек дип табылды. Җиңүчеләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та котлады.

– Тел булмаса, милләтнең киләчәге юк. Сез яшьләрне күргәч, күңелдә ышанычлы туа. Үзебезнең Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә, чит илләрдә дә татар телен саклап калуга өлеш керткәнегез өчен бик зур рәхмәтемне әйтәсем килә, – диде ул чыгышында.

«ШК» журналисты исә япон кызы Накамура Мидзуки белән аралашырга да җай тапты.

Накамура олимпиадада җиңүгә үзе дә ышанып бетә алмый.

– Татар теле – матур, мәдәниятле тел, аны бергәләп өйрәник, бөек телебезне саклыйк, – диде ул.

Кыз татар сүзләрен беренче тапкыр әбисеннән ишеткән.

– Минем әбием тумышы белән Башкортстан якларыннан. Керәшен татары булган, Александра исемле. Кызганыч, ул бүген инде вафат. Ләкин миндә татар теленә мәхәббәт уятты, татар сүзләрен өйрәтеп калдырды. 20 яшемдә Ташкентка укырга баргач, үзбәк телен өйрәнергә туры килде. Үзбәк теле татарчага охшаш икәнен аңлап алдым һәм бу телләрне ныклап өйрәнә башладым. Гаиләдә мин – берденбер бала. Әти-әнием – японнар. Ләкин ничек кенә булмасын, интернеттагы «Ана теле» онлайн мәктәбе, татар газеталары сайтлары, радиолар аша татар телен өйрәнергә тырышам. Минем йөрәгем – татар, – дип елмая Накамура.

Ул Япониядәге Цукуба шәһәрендәге университетта аспирантурада укый. Татар телендә аралашучы дуслары да бар. Казаннан Япониядә белем алучы Азат Кашапов белән дуслашкан, Мәскәүдән килгән татар кызы белән дә аралаша. Япониядә татар теле белгече Юто Хишияма белән дә элемтәдә тора.

– Татар теленең грамматикасы япон теленекенә охшаган. Шулай да татарчаны өйрәнү авыр. Көнемнең бер ике сәгатен телне өйрәнүгә багышлыйм. Япониядә татарча сүзлекләрнең булмавы да эшне катлауландыра. Шуңа да татар телен өйрәнү өчен башта русчаны үзләштерергә туры килде. Казанга килгәч, Бауман урамындагы китап кибетеннән рус телендә язылган татар дәреслекләре алдым, – ди Накамура.

Ул үзен Мәйсәрә дип тә йөртә әле. Казан федераль университетында галимә Әлфия Йосыпова шундый исем биргән аңа. Татар җырларын моңлы итеп башкаручы милли киемдәге бу кызга чынлап та әлеге исем килешеп тора. Киләчәктә, мөмкинлек туса, Казанга эшләргә килергә исәбе дә бар Накамура Мидзукиның. Ә бу юлы ул үзе Рөстәм Миңнехановны Япониягә чакырган.

Олимпиаданың төп җиңүчеләренең тагын берсе – Саба районының Эзмә авылы кызы Ризәлә Йосыпова Татарстан Президентына, республикада татар телендә белем алу мөмкинлеге тудырылганы өчен, рәхмәтен җиткерде.

ТАТАР ӨЧЕН КЕМ КӨРӘШСЕН?

«Илһам» бөтенроссия яшь иҗатчылар бәйгесе – татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уятуны күздә тота. Ел саен бәйгедә әдәби иҗатка сәләте булган яшь язучылар ачыклана. Быел да «Өметле киләчәк», «Яшь журналист», «Яшь драматург», «Яшь прозаик», «Яшь шагыйрь» номинациясендә җиңүчеләр билгеләнде. Азнакайдан Инзилә Хөсәенова Гран-при яулады.

Оештыручылар бәйгедә елдан-ел көчлерәк балалар катнашуын, шул рәвешле язучылар өчен алмаш әзерләнүен,туган телнең киләчәге өметле булуын искәртә.

Форум әкияттәге Зөһрә кыз уйланулары белән үрелеп барды. Телне саклап калу, авылларның киләчәге якты итү, өметле яшьләр, заманча җырлар турында да сөйләште персонажлар. «Шәһәрдә хәрәкәт итмәсәң, бәрәкәткә ирешә алмыйсың», – диде геройларның берсе. 100 төрле милләт вәкилләре яшәгән калада үз телеңне, гореф-гадәтләреңне саклап калу өчен һәркем хәрәкәттә булырга тиештер шул. Шагыйрь Рафис Корбан әйткәнчә:

«Татар өчен кем көрәшсен,
Көрәшмәсә татар үзе?!»

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Россия буйлап тәмле сәяхәт

Ульяновск, Томск, Кемерово өлкәсе Кулланучылар берлеге, Башкортстан товар җитештерүчеләре, Ленинград өлкәсе Кулланучылар берлегенең Гатчино сәнәгать комбинаты, Мари Эл, Ульяновск, Чуашстан, Ярославль, Вологда, Әстерхан, Пенза товар җитештерүчеләренең барысы белән Казанның Игенчеләр сарае каршындагы мәйданда оештырылган күргәзмә-ярминкәдә танышырга була.

Күргәзмә 21-22 апрель көннәрендә Казанда уза торган Россия Федерациясе үзәк советының кооператив форумы кысаларында оештырылган. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Федерациясе Үзәк советы рәисе Дмитрий Зубов, Татарстан премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов күргәзмә белән танышып йөргәндә, җитештерүчеләрнең һәркайсы кунакларны сыйларга, үзләре белән таныштырырга ашыктылар.

Ризыкларның төрлелегеннән күзләр камаша. Һәр төбәк үзенең милли йөзен, үз төбәгенең үзенчәлеген күрсәтергә тырышкан. Кыскасы, бер ярминкәдә бөтен Россия буйлап сыйлана-сыйлана сәяхәт иткән кебек буласың. Кайсы яныңа гына килмә, үзләре алып килгән ризыкларны авыз итәргә тәкъдим итәләр. Барысы да диярлек ризыкларның экологик чиста булуына басым ясый.

Ит, казылык, кондитер әйберләре бер хәл, Әстерхан өлкәсе Харабалинск районы балыкчылык берлеге ярминкәгә килүчеләрне хәтта уха белән сыйлады. Гадәти кебек тоелган ризыкларны да үзенчәлекле итеп тәкъдим итә белгәннәр. Башкортстан җитештерүчеләре талкаһнан кәнфит ясаган. Тәҗрибәләрен җыелган халык белән дә урталаштылар. Халык егылып талкан ала. Кәнфит ясарга дип?..

Башкортстан Кулланучылар берлеге вәкилләре, кайсы төбәк һәм өлкә нәрсә белән шөгыльләнүен күрсәтү өчен, мондый күргәзмәләрнең әһәмияте зур булуын билгеләп узды. «Вейра-союз» кулланучылар кооперативы бактериофаглы инновацион яңа продукциясе турында кыскача сөйләгәннән соң, Рөстәм Миңнеханов боларның кирәкле әйберләр булуын, аларны куллануның зарурлыгын белдерде.

Авыл хуҗалыгы тармагы белән сабантуй аерылгысыз кебек. Сабантуй ук булмаса да, кайбер көрәнешләрен күрергә мөмкин иде. Язның кыш белән тартышкан вакыты, тышта җил, шулай да үз-үзенә ышанган егетләр, чишенеп атып, колга башына үрмәләделәр. Әлеге бәйгедә редакциябезнең машина йөртүчесе Альберт Каюмов та катнашты. Катнашты гына түгел, ә икенче урынны алды! Тамашачылар калын курткалардан туңып торганда яланаяк, яланөс багана башына «әх» дигәнче менеп җиткән егеткә «Афәрин!» дими, ни дисең инде?!

Мәйданда күргәзмә программасы Россия төбәкләре коллективлары концерты белән дәвам итте.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

Шагыйрь эзләре буйлап... Кытайга кадәр

2010 елда Риман Гыйлемханов җитәкчелегендә бер төркем журналистлар: Гөлназ Галимҗанова, Рәмилә һәм Альбина Газизуллиналарның сөекле шагыйребез Габдулла Тукай эзләре буенча Җаекка, Казахстанга һәм Кытайга барулары, 20 мең чакрым юл узулары турында матбугаттан хәбәрдар беркем дә белми калмагандыр, шәт.

Йолдыз ШӘРАПОВА

Әлеге сәяхәт бик озын, кызыклы гына түгел, шактый аянычлы да булган – бу фидакарьләр, юл һәлакәтенә очрап, зыян да күргән иде. Ләкин еллар узган, тән җәрәхәтләре төзәлгән, ә күңелдә тирән уелып калган җылы хатирәләр, кадерле ядкарьләр күптән түгел генә «Истә калганнар» дигән китап булып дөнья күргән.

Китапның авторы – Тукай нәселе баласы, Тукай фонды рәисе Риман Гыйлемханов Казахстан һәм Кытайда Тукай исемен байрак итеп күтәрүләре турында әйтеп шаккатырды.

– Кытайда һәр татар гаиләсе Тукайның шигырьләрен яттан белә. Теле ачылган һәр бала «Туган тел»не көйли. Кайбер дәреслекләрдә Тукайны Кытайда туган дип тә язганнар, безгә, ул Кытайда булган, дип тә әйттеләр, ышанмадык кына. Биографиясендә андый юллар юк бит. Бөек шагыйрьне үзләренеке итү теләге шулкадәр көчле, – диде ул.

Китапны нәшер итү шактый мәшәкатьле булган. Хәйриячеләр эзләп, анда-монда чабып йөрергә туры килгән авторга. Ярый әле, татар рухы сагында торучы мәрхәмәтле җан – «Таттелеком» җитәкчесе Лотфулла Шәфигуллин монда да ярдәм кулы сузган. Китап, 500 данә белән генә булса да, дөнья күргән. Аны үзләре булган җирләрдәге ярдәмнәре тигән татарларга, китапханәләргә җибәргәннәр.

«Китапның тиражы аз, укый алмабыз инде», – дип борчылучыларга Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин болай диде:

– Без Тукай ядкаренә гомумән дә зур игътибар бирәбез. Соңгы елда гына бөек шагыйребез исеме белән 35 китап чыкты. Алар арасында «Истә калганнар» дигән әлеге сәяхәтнамә дә бар. Күбрәк укучы укый алсын өчен, Таткнига.ру сайтының Татар әдәбияты үзәге порталына куйдык. Шуннан кереп, бушка таныша аласыз.

ТУКАЙ УЛ – БЕЗНЕҢ ДӘҮЛӘТ!

Әйе, уйландыра торган китап бу. Тукае булган милләт зур да, горур да, көчле дә булырга тиеш. Китап шуңа ишарә. Якты җиһанда 27 ел гына яшәп калса да, гомере бик кыска булса да, дөнья әдәбияты хәзинәсенә керерлек бай мирас калдырган Тукай – чын мәгънәсендә, халык улы. Юкка гына «Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем» дип язмаган бит инде ул. Бу сүзләрдә шагыйрь олы рәхмәтен дә, горурлануын да җиткергән үз халкына. Шуңа күрә дә татар яшәгән һәрбер җирдә ул бүген дә милләттәшләребезне бергә туплый торган изге зат, пәйгамбәр булып кала бирә. Каләмдәшләребезнең озын сәфәре дә моны тагын бер тапкыр раслаган. Тукай исеме аларга төрле архивлар, музей ишекләрен ачтырган. Күп йөргән күп күргән дигәндәй, чагыштырыр нәрсәләр дә шактый булган. Әйтик, Җаекта Тукай эзләрен бик игътибар белән саклауларына сокланганнар. Анда хәтта Тукай укыган мәктәп бинасы да, ул йөргән мәчет тә элеккеге килеш сакланган. Моны Тукайга булган мәхәббәт, ихтирам белән аңлатканнар. Казахларның да үз шәхесләренә булган мөнәсәбәтен күреп шаккатканнар алар. Әбит кайчан гына әле бу халыкны укырга-язарга безнең татарлар өйрәткән булган. Риман Гыйлемханов Казаныбызда Тукай эзләрен саклаган, аның бердәнбер өе булган «Болгар» кунакханәсенең җимерелүенә бик ачына. «Кытайда Тукай китабы һәр гаиләнең өстәл китабы булган кебек, бездә дә шулаймы соң бу?» – дип тә уйлана.

Риман Гыйлемханов Тукай эзләре буйлап йөргәндә. Уңда – Уральск шәһәренең «Габдулла Тукай» татар үзәге рәисе, профессор Разак Әбүзәров.

Без үз милләтебезнең дөнья күләмендәге дәрәҗәсен бик үк аңлап бетерә алмаган халык бугай. Ромен Роллан әйткән бит: «Дәүләтен югалткан халыкның дәүләте – шәхесләре», – дип. Димәк, Тукай ул – безнең дәүләтебез.

Узган ел ирем командировкага Германиягә Бремен шәһәренә барган иде. Ул теге Бремен музыкантлары әкияте белән бәйле кала икән. Шуңа күрә алып кайткан һәр бүләгендә: кружка, китап, тастымал, магнитларын әйтеп тә тормыйм инде, берсе өстенә берсе менеп баскан ишәк, эт, әтәч, мәче рәсеме төшерелгән. Мин шунда уйлап куйдым, безнең Шүрәле (аның әле эчтәлеге теге музыкантларныкына караганда күпкә мавыктыргыч һәм игелеклерәк тә) бездә шулай популяр микән? Һәрхәлдә, минем Шүрәле сурәте төшкән чынаяк күргәнем дә, аннан чәй эчкәнем дә юк. Соңгы елларда Казаныбыз туристлар мәркәзенә әйләнде. Тукай геройлары халкыбызны да, башкалабызны да, республикабызны да дөньяга күбрәк танытырга булышыр иде. Риман әфәнде үзенең «Истә калганнар» китабында шул фикерләрне әйтергә теләгән дә инде. Китапны укып чыгучылар башта Тукай белән, аннары шундый бөек шәхесне биргән татар халкы белән горурланмыйча калмаслар, шәт.

Китапка шагыйрь Роберт Әхмәтҗановның шигъри юлларын эпиграф итеп алу да әлеге сәяхәтнең һәм китапның бөтен максатын ачып сала:

Эзләмәсәк бүген Тукайны без
Туар чорлар нәрсә әйтерләр?

ПОЧТАДАН

«Мин татарча знаю»

Беркөнне «Тукай мәйданы» тукталышына кадәр дип шәһәр автобусына утырдым. Яшь кенә кондуктор кызга, транспорт картасы белән юлда йөрү өчен түләгәннән соң, «Рәхмәт!» – дидем. Миңа ачуланып карап тора. «Рәхмәт!» – дидем кабат. Янымда утырган өлкән яшьтәге рус әбисе: «Дочка, он тебе спасибо сказал», – дип, теге кызга аңлатты. Кондуктор кыз: «Почему по-русски не говорит», – дип кырын карап, урынына барып утырды.

Автобуста кондуктор булып эшләүче, Татарстанда яшәүче бу кыз «исәнмесез», «сау булыгыз», «рәхмәт» сүзләрен генә булса да белергә тиештер бит?

Тукталышта басып торганда, мәктәптә укучы бер татар баласыннан да туган телен беләме икән дип кызыксындым. Кызганыч, ул да: «Знаю», – дип җавап бирде. Татар яшьләре күбесенчә урыс теленде аралаша шул. Балаларның күбесе «школ»да укый, без укыган «мәктәп»ләр үткәндә калды.

Тел – кешегә бирелгән бик кыйммәтле бүләк. Ул сүз билгеле бер халыкны, аның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, яшәешен үз эченә ала. Ана теле белән кешенең яшәешенә ныклы нигез салына. Туган тел белән сабый үз халкының улы яки кызына әверелә, шуңа күрә туган телне, бала чактан ук күркәм милли тәрбия белән, сабыйның керләнмәгән гөнаһсыз күңеленә сеңдерергә кирәк. Ул искиткеч мөгаллим –туган тел – үзенә хас алымнар белән бик күп нәрсәне җиңел генә аңлата. Туган телнең мөһимлегенә шикләнүчеләр юктыр. Бала үзенең ана телен белергә тиеш, бу – яшәеш һәм табигать кануны.

Соңгы елларда башкалабыз Казанда татар балалар бакчалары ача башладылар. Тәрбиячеләр арасында татар кызлары гына түгел, руслар да бар, шулай булгач, анда татар мохите тудырып булмый. Саф татар балалар бакчасында да рәхәтләнеп русча аралашалар. Татар мәктәпләрендә дә күпләп урыс телләләрне ала башладылар, хәтта татар гимназияләрендә дә! Үз-үзебезне алдыйбыз түгелме соң?

Кеше 80 процент очракта әйләнә-тирә мохитне күреп үзләштерә, дип яза галимнәр. Татарстанда күп кенә оешма, кибет, музей, спорт корылмаларының исемнәре рус телендә. Мәсәлән, УНИКС баскетбол командасы, «Санкт-Петербург» волейбол үзәге, «Мәскәү» спорт комплексы. Үзебезнең лаеклы милли атамаларыбыз юкмыни?

Без Татарстанда – татарларның туган илендә яшибез. Милләтебезнең үз канунныры, гореф-гадәтләре, йолалары бар. Алар да үз каһарманнары белән горурланырга хаклыдыр бит! Татар теленең фәндә, көнкүрештә чын дәүләт теле була алганы юк. Радио-телевидениедә татар телендәге тапшырулар гаять дәрәҗәдә аз. Балалар өчен биграк тә. Татарча мультфильмнар, татар әкиятләрен ешрак күрсәтергә кирәк. Татар телен өйрәнү курсларыннан файдалану мөмкинлеген киңәйтү дә соралa. Белгечләр, милли кадрлар әзерләү өчен үзебезнең милли югары уку йорты һичшиксез булырга тиеш.

Нияз БИШБАЛТА,
Казан.

Фотолар: tatar-inform.ru

«Йолдызлык» балаларының ни өчен Гран-при аласы килми?

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә «Созвездие-Йолдызлык–2017» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең йомгаклау концерты узды.

Алисә САБИРОВА

Үнкиде ел рәттән үткәрелгән фестивальнең быелгы Гран-при иясе дип Зәй шәһәренең «Азаль» вокал-хореография ансамбле (вокал номинациясе) белән Лениногорск шәһәренең «Пируэт» ансамбле (хореография номинациясе) танылды. Җиңүчеләрне Татарстан Республикасы премьер-министры Алексей Песошин тәбрикләде.

– 17 ел эчендә фестиваль республиканың иҗтимагый, мәдәни тормышының аерылгысыз бер өлешенә әйләнде. Бу фестиваль генә түгел, бу үзе бер миссия. Ул яшь сәләтләргә тормышка юллама бирә. Республиканың әлеге нәни энҗе бөртекләрен туплаган өчен, педагогларга зур рәхмәтемне җиткерәсем килә, – диде Алексей Песошин.

Сәхнә артында исә балалар, үзләренә хас самимилек белән: «Гран-при алмасак ярар иде», – ди. «Йолдызлык»ның иң югары бүләген алган төркем киләсе елда фестивальдә катнаша алмый бит. Сабыйлар шуңа борчыла.

Башка еллар белән чагыштырганда, быел катнашучылар саны тагын 20 процентка арткан. Ә фестивальнең зона этабында 21 меңнән артык бала үзен сынап карарга өлгерде. Суперфиналга исә 5100 бала чыкты. Биредә Татарстанның 45 муниципаль үзәгеннән тыш, Мәскәү, Чиләбе, Әстерхан, Ульяновск, Волгоград шәһәрләреннән, Башкортстан белән Кырым республикаларыннан да чыгыш ясаучылар бар иде. «Созвездие-Йолдызлык» инде икенче ел рәттән Россиянең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе җитәкчелегендә үтә. Ул – ил күләмендә халыкара дәрәҗәгәирешкән бердәнбер балалар проекты. Бу юнәлештә башкалар Татарстанга көнләшеп һәм үрнәк итеп карый диган фикердә Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Сулима.

– Татарстан – бәхетле балалар яши торган республика. Россиянең башка субъектлары бездә шундый мөмкинлекләр булдырылганга көнләшеп карый. Балаларга иң яхшы концерт мәйданчыкларында чыгыш ясарга мөмкинлек бирелүе дә моңа бер дәлил, – дип, министр урынбасары балаларга дүртенче чирекне уңышлы тәмамлауларын теләде.

Моннан тыш, «Йолдызлык» алдында балаларга тәрбия бирү бурычы да тора бит әле. Әйтик, дистәләгән жюри әгъзалары, педагоглар һәр зона этабында катнашучыларга бушлай мастер-класс бирә. «Мөслим бизәкләре» бию төркемен генә алыйк, алар бүгенге көнгәчә Татарстанның халык артисты, республиканың дәүләт җыр һәм бию ансамбле баш балетмейстеры Раилә Гарипова дәресләрен яратып искә ала. Бу дәресләрдән соң төркемдәге кызларның барысының да хореограф буласы килә.

– Бию белән ун ел шөгыльләнәм инде. Хәзер унынчы сыйныфта укыйм, булачак һөнәремне сайлар вакыт. Әлегә медицина белән хореография арасында икеләнәм. «Йолдызлык» яңа дуслар булдырды. Башкаларга карап сокланып, үрнәк алып, үзеңнең мөмкинлекләреңне үстерергә этәргеч бирде, – ди Инзилә Сәфәргалиева.

2010 елда фестиваль кысаларында «Мөслим бизәкләре» Мәскәү сәхнәсендә дә чыгыш ясарга өлгерә. Быел исә биюче кызлар лаеклы өченче урынга ия булды.

Сәләтле балаларны бәйрәм белән котларга Татарстанның бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Гүзәл Удачина да килгән иде.

– «Йолдызлык» инде күптәннән бәйге кысаларыннан чыкты. Бүген ул – зур, көчле балалар һәм яшьләр иҗат хәрәкәте. Бала хокукларын яклау турында күп сөйләшәбез. Менә мондый бәйгеләр аны яклау өчен иң яхшы ысул, – диде Гүзәл Удачина.

2006 елдан фестиваль җиңүчеләре Татарстан Президенты исеменнән махсус стипендия белән бүләкләнә башлады. Хореография юнәлешендә Гран-при алучы – 150 мең, вокал буенча иң зур бүләккә ия булучы 100 мең сумлык премия ала. Балаларны гына түгел, укытучыларны да онытмый «Йолдызлык». Бу көнне балаларны иҗат дөньясына гашыйк иткән 50 мөгаллим Мәгариф һәм фән министрлыгы исеменнән 30 меңлек грант отты. Иң яхшы укытучылар «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исемгә лаек булды. 17 ел эчендә «Йолдызлык»та балкыган 22 бала Россия театр сәнгате университетында (ГИТИС) белем алу хокукына ирешә. Бүген исә анда тагын 26 бала укый.

Балалар гына түгел, «Йолдызлык»ның илһам чыганагы булган Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, фестивальнең генераль продюсеры Дмитрий Туманов та бүләксез калмады. Аңа Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы белән Президент каршындагы мәдәниятне үстерү фонды тарафыннан мактау грамоталары тапшырылды.

Суперфинал «Йолдызлык»ның тагын бер елына нәтиҗә ясаса да, аның әле башкарасы эшләре җитәрлек. Фестиваль быелдан республика авылларына, районнарына гастрольләрен яңартты. Халыкара дәрәҗәдә оештырылган бушлай концертны инде Яңа Чишмә, Аксубай районнары карарга өлгерде. Җәй көне 200 бала Кырымда уздырылган «Созвездие-Йолдызлык» җәйге сменасында катнашачак. Биредә яшь сәләтләр Кара диңгез флоты диңгезчеләре, Севастополь, Бакчасарай шәһәр халкы өчен концерт номерлары куячак.

Шәһри Казан

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 705. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы